ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 30 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында” 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 9 өлешендә:

а) 1 пунктта “барлыгы 30дан артык фатиры булмаган” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

“$2^1$) идарә итүче оешма;”;

2) 3 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктында “региональ операторның мөлкәтен формалаштыру һәм эшчәнлеге тәртибен билгеләү,” сүзләреннән соң “конкурс нигезендә региональ оператор җитәкчесен билгеләп кую тәртибе,” сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, шушы ук Законның 2015 елның 1 гыйнварыннан үз көченә торган 1 статьясындагы 1 пунктының “б” пунктчасыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2014 елның 20 ноябре
№ 90-ТРЗ